ДҮШӘМБЕ
5 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 29 (5829)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, тенге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Мехчылар чакыруына практик эш белән җавап бирик!

Бөек Социалистик революциянең даһилары Ленин һәм Сталин инициативасы буенча төзелгән Татарстан республикасы үзенең XX еллык юбилеен бәйрәм итәргә хәзерләнә. Бөек тантана көне—25 нче июньгә 140 көн калды.

Үткән XX еллык чор—ул большевиклар партиясе җитәкчелегендә, бөтен Советлар Союзының актив ярдәме белән республикабызны барлык чаралар белән үстерү, аны кызу рәвештә алга җибәрү чоры булды.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы гүзәл юл үтте. Патша хөкүмәтенең артта калган, хәерче губернасы урнында, түзеп тормаслык эксплоатация, хокуксызлык һәм милли изү булган урында, хәзер алдынгы социалистик республика үсте һәм ныгыды. Аның байрагында хәзер Ленин ордены балкый.

Татарстан үзенең XX еллык юбилеенә тарихи зур казанышлар белән килә, аның йөзе танымаслык булып, индустриаль-аграр республика булып әверелде. Ул үзенең бай экономикасы, культурасы белән генә түгел, бәлки иптәш Сталин тәрбияләп үстергән кешеләре белән дә зур дан яулап алды.

XX еллыкка хәзерлек республикабыз хезмәт ияләренең яңа омтылышын, яулап алынган казанышларны ныгыту, тагын да зуррак уңышларга ирешү омтылышын тудырды. Авылларда, заводларда һәм фабрикаларда, яңа төзелешләрдә, культура учреждениеләрендә бәйрәм хөрмәтенә эшлекле хәзерлек җәелдерелә. Газетабызның шушы көннәрдә генә чыккан номерларында авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсенең һәм мехчыларның мөрәҗәгатьләре урнаштырылды. Бу факт үзе генә дә масса активлыгының ачык күрсәткече булып тора ала.

Мехкомбинаты эшчеләре һәм инженер-техник работниклары орденлы республикабызның данлыклы XX еллыгын производствода яңа уңышлар белән истә калдыру хөрмәтенә социалистик ярыш оештыруның инициаторлары булдылар, алар Москва шәһәрендәге инструменталь заводы коллективы мөрәҗәгатенә иң беренче булып кушылдылар, хезмәт җитештерүчәнлегенең бишьеллык планын дүрт елда үтәү өчен ярышны киңәйтүче, үстерүче булдылар.

Москвалылар чакыруы илебезнең барлык хезмәт ияләре тарафыннан, шул исәптән республикабызда да гаять зур шатлык белән, политик һәм производство активлыгының яңа күтәрелеше белән каршыланды. Совет патриотлары хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югары күтәрү өчен, бөек социалистик Ватаныбызның экономик һәм оборона куәтен ныгыту өчен социалистик ярышны киң җәелдерделәр. Бөек ярышка халык хуҗалыгының әледән-әле яңа тармаклары кушылалар.

Ярыш үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә, стахановчылык хәрәкәтен яңа формалар белән баета. Берничә профессияне үзләштерү һәм берьюлы күп станокларда эшләү хәрәкәте көннән-көн киң колач ала бара. Бай техниканы ныклап үзләштергән, үз эшләренең оста мастерлары булып күтәрелгән йөзләрчә, меңнәрчә стахановчыларыбыз хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә моңа кадәр күрелмәгән югары күрсәткечләр бирәләр.

Мәсәлән, С. М. Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводында 7 нче цех стахановчылары Ураинская, Большакова һәм Маркухина иптәшләр 12 аппаратта эшләү урнына берьюлы 30 аппаратка хезмәт күрсәтә башладылар. Бу башлангычка аппаратчылардан Цивильский, Горожанина, Булданов, Соболева һәм башка иптәшләр дә кушылдылар. Завод коллективы 1940 нчы елның беренче яртысы планын вактыннан элек, 25 нче июньгә—республикабызның 20 еллык юбилее көненә арттырып үтәү өчен намус белән көрәшә. Серго заводы, Вахитов исемендәге жиркомбинат, „Спартак“ һәм башка предприятиеләр дә еллык планны вактыннан элек үтәү йөкләмәсен алдылар.

Мехчылар коллективы, республикабызның XX еллыгы хөрмәтенә, 1940 нчы елның беренче яртысы планын 25 нче июньгә үтәргә, хезмәт җитештерүчәнлеген 1939 нчы ел белән чагыштырганда 15 процентка күтәрергә, 500 тонна күмергә, 300 мең киловатт-сәгать электроэнергиягә экономия ясарга булды. Йөкләмә практик эш белән ныгытыла. Январь ае планының комбинат буенча 106,6 процент итеп үтәлүе әнә шул турыда сөйли. Беренче, өченче һәм кызыл байраклы дүртенче фабрикалар аеруча яхшы эшлиләр. Алар январь ае планын 112—113 процент итеп үтәделәр.

Мехчылар мөрәҗәгате социалистик ярыш байрагын тагын да югарырак күтәрүдә, стахановчылык хәрәкәтен һәм аның яңа формаларын тагын да ныгытуда, киңәйтүдә көчле этәргеч булды. Мәсәлән, В. И. Ленин исемендәге завод коллективы ярты еллык планны 25 нче июньгә үтәү, илгә планнан тыш бер ярым миллион сумлык экономия бирү, моның өчен уйлап табу тәкъдимнәрен кертү, чималны, ягулыкны һәм электро-энергияне саклык белән тоту йөкләмәсен алды. 25 нче июньгә 4 катлы яңа торак йорт төзелешен төгәлләүне, завод эшчеләре арасында укый-яза белмәүчелекне һәм аз укый-яза белүчелекне тулысынча бетерүне ышандырды. Казшвейпром артеле членнары, индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәр эшләү фабрикасы, язу машиналары заводы эшчеләре дә чакыруга яңа йөкләмәләр алу белән җавап бирәләр.

Бурыч—массаның бу активлыгын ныгытудан, аны тагын да киңәйтүдән, масса активлыгына большевистик оператив җитәкчелек итүдән, социалистик ярышка һәрбер предприятиенең, һәрбер хезмәт иясенең кушылуын тәэмин итүдән, алынган йөкләмәләрнең һич сүзсез үтәлүенә ирешүдән гыйбарәт. Партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмалары бу эшне турыдан-туры үз кулларына алырга тиешләр.

Социалистик ярыш байрагын тагын да югарырак күтәрик! Республикабызның XX еллыгын яңа һәм зур казанышлар белән билгеләп үтик!

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

„ГЕОРГИЙ СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧ ПАРОХОДЫНДА ХӘРӘКӘТТӘ КАТНАШУЧЫЛАРГА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСМЕ БИРҮ ТУРЫНДА

1. Арктикадагы гаять авыр шартларда героик хәрәкәт үткәргән өчен, фәнни тикшеренүләрнең киң программасын үтәгән өчен һәм шул вакытта күрсәткән батырлыклары һәм тырышлыклары өчен **Ленин ордены** һәм **„Алтын йолдыз“** медале белән берлектә **Советлар Союзы Герое** исме бирергә:

1. „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының капитаны Константин Сергеевич **Бадигинга.**
2. „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының помполиты Дмитрий Григорьевич **Трофимовка.**
3. Капитанның өлкән ярдәмчесе Андрей Георгиевич **Ефремовка.**
4. Гидрограф Виктор Харлампиевич **Буйницкийга.**
5. Икенче механик Сергей Дмитриевич **Токаревка.**
6. Өченче механик Всеволод Степанович **Алферовка.**
7. Радист Александр Александрович **Полянскийга.**
8. Радист Николай Михайлович **Бекасовка.**
9. Боцман Дмитрий Прокофьевич **Буторинга.**
10. Машинист Иосиф Маркович **Недзвецкийга.**
11. Машинист Николай Сергеевич **Шарыповка.**
12. Врач Александр Петрович **Соболевскийга.**
13. Матрос Ефрем Иванович **Гаманковка.**
14. Кочегар Иван Иванович **Гетманга.**
15. Повар Павел Власович **Мегерга.**

2. К. С. Бадигинга, Д. Г. Трофимовка, А. Г. Ефремовка, В. Х. Буйницкийга, С. Д. Токаревка, В. С. Алферовка, А. А. Полянскийга, Н. М. Бекасовка, Д. П. Буторинга, И. М. Недзвецкийга, Н. С. Шарыповка, А. П. Соболевскийга, Е. И. Гаманковка, И. И. Гетманга һәм П. В. Мегерга һәрберсенә акчалата 25.000 сум бүләк бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

„ИОСИФ СТАЛИН“ БОЗВАТКЫЧЫ ЭКИПАЖЫН СССР ОРДЕННАРЫ һӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Арктика бозларыннан чыгару буенча хөкүмәт заданиесен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм бу эштә батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен „Иосиф Сталин“ бозваткычы экипажын бүләкләргә:

КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ ОРДЕНЫ БЕЛӘН

1. „Иосиф Сталин“ бозваткычы капитанының дублеры Борис Николаевич **Макаровны.**
2. „Иосиф Сталин“ бозваткычы капитанының өлкән ярдәмчесе Эрнест Германович **Румкене.**

ХЕЗМӘТ КЫЗЫЛ БАЙРАГЫ ОРДЕНЫ БЕЛӘН

1. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән механигы Андрей Васильевич **Неупокоевны.**
2. „Иосиф Сталин“ бозваткычының икенче механигы, элек „Почет билгесе“ ордены белән бүләкләнгән Валентин Федорович **Донаусовны.**
3. „Иосиф Сталин“ бозваткычының инженер-электригы Василий Александрович **Цыкуновны.**
4. „Иосиф Сталин“ бозваткычының врачы Александр Петрович **Смоленскийны.**
5. „Иосиф Сталин“ бозваткычының буфетчицасы Марфа Митрофановна **Павлованы.**
6. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән машинисты Иван Михайлович **Сычевне.**
7. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс кочегары Андрей Петрович **Савочкинны.**

ПОЧЕТ БИЛГЕСЕ ОРДЕНЫ БЕЛӘН

1. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс машинисты Михаил Николаевич **Колобовны.**
2. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өченче механигы Александр Маркович **Шатуровны.**
3. „Иосиф Сталин“ бозваткычының радисты Иван Павлович **Григорьевны.**
4. „Иосиф Сталин“ бозваткычының боцманы Александр Иванович **Мишинны.**
5. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән рулевое Александр Иванович **Михайловны.**
6. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс матросы Сергей Кузьмич **Полухинны.**
7. „Сталинец“ газетасының редакторы Абрам Лазарович **Любовичны.**
8. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән машинисты Михаил Михайлович **Виноградовны.**
9. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс машинисты Макс Юльевич **Бромбергны.**
10. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән машинисты Василий Степанович **Галзновны.**
11. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс кочегары Михаил Ильич **Нижникны.**
12. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс кочегары Алексей Иванович **Никитинны.**

„ХЕЗМӘТТӘГЕ БАТЫРЛЫК ӨЧЕН“ МЕДАЛЕ БЕЛӘН

1. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс матросы Серафим Семенович **Гольцевны.**
2. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс матросы Александр Петрович **Макарихинны.**
3. „Иосиф Сталин“ бозваткычының икенче класс матросы Николай Петрович **Русановны.**
4. „Иосиф Сталин“ бозваткычының икенче класс матросы Иван Данилович **Мельниковны.**
5. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән машинисты Василий Харитонович **Решетниковны.**

„АЕРУЧА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТКӘН ӨЧЕН“ МЕДАЛЕ БЕЛӘН

1. „Иосиф Сталин“ бозваткычы капитанының икенче ярдәмчесе Вячеслав Михайлович **Нашатыревны.**
2. „Иосиф Сталин“ бозваткычының сперисты Сергей Михайлович **Свечихинны.**
3. „Иосиф Сталин“ бозваткычының дүртенче механигы Петр Николаевич **Соколовны.**
4. „Иосиф Сталин“ бозваткычының радио мөдире, элек „Хезмәт Кызыл байрагы“ һәм „Почет билгесе“ орденнары белән бүләкләнгән Евгений Николаевич **Гершевичны.**
5. „Иосиф Сталин“ бозваткычының балта остасы Василий Яковлевич **Орловны.**
6. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс матросы Иван Иванович **Мурашевны.**
7. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс матросы Иван Васильевич **Шараповны.**
8. „Иосиф Сталин“ бозваткычының азык мөдире, элек „Кызыл йолдыз“ ордены белән бүләкләнгән Иван Александрович **Корольковны.**
9. „Сталинец“ газетасының наборщигы Гаврил Васильевич **Суминны.**
10. „Иосиф Сталин“ бозваткычының җыештыручысы Леонид Юрьевич **Зеленскийны.**
11. „Иосиф Сталин“ бозваткычының кер юучысы Анна Николаевна **Николаеваны.**
12. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән машинисты Александр Агапович **Агаповны.**
13. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән машинисты Павел Алексеевич **Ошмаринны.**
14. „Иосиф Сталин“ бозваткычының трюм машинисты Максим Григорьевич **Спарышевны.**
15. „Иосиф Сталин“ бозваткычының трюм машинисты Михаил Свиридович **Цыганенконы.**
16. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс машинисты Борис Казимирович **Буцконы.**
17. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс машинисты Владимир Григорьевич **Гагаринны.**
18. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс машинисты Павел Исаакович **Семеновны.**
19. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс машинисты Григорий Александрович **Волковны.**
20. „Иосиф Сталин“ бозваткычының икенче класс машинисты Владимир Филиппович **Акимовны.**
21. „Иосиф Сталин“ бозваткычының электригы Алексей Витальевич **Афанасьевны.**
22. „Иосиф Сталин“ бозваткычының электригы Михаил Григорьевич **Жирковны.**
23. „Иосиф Сталин“ бозваткычының кочегарлар старшинасы Александр Андрианович **Кириловны.**
24. „Иосиф Сталин“ бозваткычының кочегарлар старшинасы Леонид Алексеевич **Савельевны.**
25. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс кочегары Арсений Михайлович **Васильевны.**
26. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс кочегары Дмитрий Александрович **Володинны.**
27. „Иосиф Сталин“ бозваткычының беренче класс кочегары Дмитрий Дмитриевич **Германовны.**
28. „Иосиф Сталин“ бозваткычының икенче класс кочегары Александр Александрович **Виноградовны.**
29. „Иосиф Сталин“ бозваткычының икенче класс кочегары Василий Егорович **Семеновны.**
30. „Иосиф Сталин“ бозваткычының өлкән радисты Александр Михайлович **Мошкинны.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы указы

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Ленин ордены белән бүләкләү турында

Төньяк Боз Океаны һәм Гренландия диңгезе бозларында 812 көн дәвам иткән героик хәрәкәт өчен „Георгий Седов“ бозваткыч пароходын **Ленин ордены белән бүләкләргә.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы указы

„Иосиф Сталин“ бозваткычын Ленин ордены белән бүләкләү турында

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Арктика бозларыннан чыгару буенча хөкүмәт заданиесен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен „Иосиф Сталин“ бозваткычын **Ленин ордены** белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы указы

Н—171 самолеты экипажын бүләкләү турында

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходы хәрәкәтен куркынычтан саклау буенча хөкүмәт заданиесен бик яхшы итеп үтәгән өчен Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсенең Котып авиациясенең Рудольф атавындагы Н—171 самолеты экипажы составын бүләкләргә:

Кызыл Йолдыз ордены белән

Н—171 самолеты экипажының командиры, элек Ленин ордены белән бүләкләнгән Георгий Константинович ОРЛОВНЫ.

Н—171 самолетының пилоты Эндель Карлович ПУСЕПНЫ.

Н—171 самолетының штурманы, элек Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнгән Лев Миронович РУБИНШТЕЙННЫ.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән

Н—171 самолетының борт-механигы, элек „Кызыл Йолдыз“ ордены белән бүләкләнгән Павел Павлович ПЕТЕНИННЫ.

Почет билгесе ордены белән

Н—171 самолетының борт-механигы, элек „Хезмәт Кызыл Байрагы“ ордены белән бүләкләнгән Иван Васильевич МЕЛЬНИКОВНЫ.

Н—171 самолетының борт-механигы, элек „Хезмәт Кызыл Байрагы“ ордены белән бүләкләнгән Евгений Илларионович ЧЕРНЫШЕВНЫ.

„Хезмәттәге батырлык өчен“ медале белән

Н—171 самолетының борт—радисты, элек „Хезмәт Кызыл Байрагы“ ордены белән һәм „Почет билгесе“ ордены белән бүләкләнгән Олег Архипович КУКСИННЫ.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы указы

Советлар Союзы Герое Иван Дмитриевич Папанинны икенче „Алтын йолдыз“ медале белән бүләкләү турында

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Арктика бозларыннан чыгару буенча хөкүмәт заданиесен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм бу эштә Советлар Союзы Герое дигән исем алырга хокук бирерлек геройлык күрсәткән өчен,—хөкүмәт экспедициясе начальнигы Советлар Союзы Герое Иван Дмитриевич **Папанинны икенче „Алтын йолдыз“ медале** белән бүләкләргә һәм аның бронзадан бюстен ясатып туган җирендә постаментка куярга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль,
3 февраль, 1940 ел.

СССР Верховный Советы Президиумы указы

„Иосиф Сталин“ бозваткычының капитаны М. П. Белоусовка Советлар Союзы Герое исме бирү турында

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Арктика бозларыннан чыгару буенча хөкүмәт заданиесен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен „Иосиф Сталин“ бозваткычының капитаны Михаил Прокофьевич **Белоусовка Ленин ордены** һәм **„Алтын йолдыз“** медале белән берлектә **Советлар Союзы Герое** исме бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Җәнлек аулаучы „Мурманец“ пароходы экипажының членнарын бүләкләү турында

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын бозлар арасыннан чыгарган вакытта бозларны күзәтү буенча хөкүмәт заданиесен бик яхшы итеп үтәгән өчен бүләкләргә:

Хезмәт кызыл байрагы ордены белән

Җәнлек аулаучы „Мурманец“ пароходының капитаны Георгий Федорович **Сулаковны.**

„Почет билгесе“ ордены белән

Җәнлек аулаучы „Мурманец“ пароходының помполиты Силантий Никандрович **Никаноровны.**

„Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән

Җәнлек аулаучы „Мурманец“ пароходының өлкән механигы, элек Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Александр Иванович **Легкийны.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Җәнлек аулаучы „Мурманец“ пароходын Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләү турында

„Георгий Седов“ бозваткыч пароходын бозлардан чыгарганга кадәр Гренландия диңгезендә бозларны күзәтү эшен үрнәк булырлык итеп үткәргән өчен җәнлек аулаучы „Мурманец“ пароходын **Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләргә.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
3 февраль, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

3 нче февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның сугыш объектларына уңышлы бомбардировка ясады.

ХРОНИКА

СССР Верховный Советы Президиумы, СССР белән Болгария арасында сәүдә һәм диңгездә йөрү турында 1940 нчы елның 5 нче январенда Москва шәһәрендә төзелгән договорны 1940 нчы елның 3 нче февралендә ратификацияләде.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

КАДРЛАРНЫҢ ТЕОРЕТИК БЕЛЕМНӘРЕН КҮТӘРҮ ӨЧЕН!

Саба районында коммунистлардан, комсомолецлардан һәм партиясезләрдән 470 кеше ВКП(б) тарихын үзлегеннән өйрәнә.

НКВД ның район бүлеге, райпотребсоюз, Заготзерно һәм Килдебәк авылы янындагы партоешмалар пропаганда эшен аеруча яхшы оештырдылар. Бу оешмалардагы коммунистлар барсы да партия тарихын өйрәнәләр, лекцияләргә, консультацияләргә системалы рәвештә йөриләр, партоешма секретарьлары аларга конкрет ярдәм итәләр: тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре, иптәшләрчә беседалар, консультацияләр оештыралар. НКВД бүлеге начальнигы Шакиров, урта мәктәп директоры Биктащев, райкомол секретаре Хәйруллин иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н тулысынча өйрәнеп, конспект төзеделәр. Хәзер алар марксизм-ленинизм классикларының аерым әсәрләрен өйрәнәләр. Банк управляющие Юсупов, район газетасы редакторы урынбасары Галиева һәм тулы булмаган урта мәктәп директоры Шәйхетдинов иптәшләр V—VII нче бүлекләрне өйрәнү өстендә эшлиләр.

Укытучылардан Биктимирев, Кирсанов, Батталов, Камаев, Камаева, Юлмитов, агрономнардан Камалов, Алтынбаев, Зарипов иптәшләр дә партия тарихын өйрәнүдә яхшы күрсәткечләр бирүгә ирештеләр.

Районда партия тарихын өйрәнүдә үрнәк булырлык иптәшләр шактый күп. Партия тарихын тырышып өйрәнүче, үзләренең теоретик артталыкларын бетерү өстендә эшләүче иптәшләр җитәкче постларга күтәреләләр. Мәсәлән, элек авыл советы председателе булып эшләгән иптәш Нуриев ВКП(б) райкомының инструкторы итеп, местком председателе иптәш Кирсанов райкомның кадрлар бүлеге инструкторы итеп, бухгалтер иптәш Батталов пропагандист итеп күтәрелде.

Парткабинет партия тарихын өйрәнүчеләргә якыннан торып булышлык итә. Парткабинетта „кыскача курс“ның барлык бүлекләре буенча да альбомнар, кулланма пособиеләр бар.

1939 нчы елны 16 тапкыр лекция оештырылды, 37 тапкыр групповой һәм 51 тапкыр индивидуаль консультацияләр үткәрелде. Актив өчен һәм колхозчылар өчен 103 тапкыр доклад куелды, шуның 53 е авылларда булды.

Бу үткәрелгән чаралар партия тарихын өйрәнүчеләргә бик зур ярдәм иттеләр.

Үзләренең политик артталыкларын бетерү өстендә җитәрлек эшләмәүчеләр дә бар әле. Райфо мөдире Хәбибрахманов, сәламәтлек саклау бүлеге мөдире Салихов, РОНО мөдире И. Ильин, судья Нәбиев иптәшләр „кыскача курс“ның 1—2 нче бүлекләреннән узганнары юк. Алар парткабинетка лекцияләргә һәм консультацияләргә йөрмиләр. Түгәрәк членнарыннан Сибгатуллин, Низамиев, Ишниязов, Гайнетдинов, Баһаветдинов һәм Гарипов иптәшләр дә занятиеләргә начар йөриләр.

Түбән Шытсу, Мичән авылларындагы һәм Леспромхоз янындагы партоешмалар (секретарьлары Фәлахов, Галимҗанов, Ковельков иптәшләр) пропаганда эшенә җитәкчелек итмиләр, ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр белән тәҗрибә уртаклашу киңәшмәләре һәм иптәшләрчә беседалар оештырмыйлар. Алар кемгә нинди ярдәм кирәклеген дә белмиләр, хәтта аларда партия тарихын өйрәнүчеләрнең учеты да юк. Бу партоешма секретарьлары үзләре дә партия тарихын өйрәнмиләр.

Партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә практик ярдәм күрсәтүдә парткабинетның да кимчелекләре бар. Парткабинетка индивидуаль консультациягә йөреш начар. ВКП(б) райкомы 8 кешене консультант итеп раслаган булса да, аларның күбесе эшләми. Мәсәлән, Мөхәмметшин һәм Фазлиев иптәшләр бер тапкыр да консультация үткәргәннәре юк. ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторлары кайчан киләчәкләрен алдан хәбәр итмиләр яки бер генә көн алдан белдерәләр, күп вакытта көтмәгәндә килеп төшәләр. Шунлыктан, лекцияләр хәзерлексез үткәреләләр, иптәшләр хәзерләнеп килә алмыйлар.

Районда колхоз активы арасында пропаганда эшенең куелышы канәгатьләнерлек түгел. Алар өчен популяр докладлар бик аз була. ВКП(б) уставын, Сталин Конституциясен һәм СССР тарихын өйрәнү эше җитәрлек оештырылмаган, политграмота түгәрәкләре юк. Партия пропагандасындагы бу кимчелекләр бетерелергә тиеш.

И. Гарипов.

ВКП(б) ның Кукмара район комитетының партия кабинетында. РӘСЕМДӘ: коммунистлар (сулдан) Ф. Герасимов һәм Ф. Никитин иптәшләр консультациягә хәзерләнү өчен китаплар сайлыйлар.

А. Михайлов фотосы.

ПАРТИЯНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘР АКТИВЫ ҖЫЕЛЫШЫ

3—4 нче февральдә партиянең Казан шәһәр активының җыелышы булып узды. Җыелышта, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының VIII нче пленумы йомгаклары һәм Казан шәһәр партия оешмасының чираттагы бурычлары турында партиянең шәһәр комитеты секретаре иптәш Бычков доклад ясады.

Ул үзенең докладында, авыл хуҗалыгы өлкәсендә яулап алынган зур казанышларга тукталды һәм Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе бу казанышларның ачык демонстрациясе булуы турында сөйләде. Шулай ук докладчы узган елны авыл хуҗалыгының байтак тармакларында җидди кимчелекләр булуы турында һәм аларның быел кабатланырга тиеш түгеллеге турында әйтеп узды.

Иптәш Бычков язгы чәчүгә хәзерлек эшләренең торышы һәм бу өлкәдә республика оешмалары алдында торган конкрет бурычларга тукталды.

Аннары, докладчы ВКП(б) сафларына яңа членнар кабул итү һәм яшь коммунистларны тәрбияләү мәсьәләләренә күчте. Ул, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарлары һәм сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталин докладь белән рухланган совет халкында производство, политик активлык үсү турында, киң хезмәт ияләре массасы каршында партиябезнең авторитеты тагын ка нык үсүе турында сөйләде.

Узган елны партиянең Татарстан оешмасы сафлары Ленин—Сталин партиясе эшенә ахрынача бирелгән, практик эштә сыналган, иң алдынгы кешеләр хисабына 57,4 процентка үсте. Шулай ук яшь коммунистларны политик тәрбияләү һәм үстерү буенча да шактый зур уңышларга ирешелгән. Узган елның соңгы алты аенда җитәкче эшләргә күтәрелүчеләрнең 30 проценты яшь коммунистлардан гыйбарәт.

Ләкин шулар белән бергә, партия сафларына кабул итү мәсьәләсендә булсын, яшь коммунистларны тәрбияләү мәсьәләсендә булсын кайбер партоешмаларның эшендә җидди кимчелекләр бар әле. Партия сафларына очраклы кешеләрнең үтеп керүе, кайбер яшь коммунистларның партия дисциплинасын бозу фактлары бар. Мәсәлән, Ленин исемендәге завод партоешмасында П. дигән кешене партия сафына алалар. Соңыннан аның меньшевиклар партиясендә торганлыгы беленә. 4 нче ясалма каучук заводы партоешмасында да партия сафларына очраклы кешеләрне алу фактлары булды.

Иптәш Бычков стажлары тулып үткән кандидатларны ВКП(б) членлыгына кабул итү, хатын-кызларны һәм төп профессия кешеләрен партия сафларына тарту буенча күпчелек партоешмаларның йомшак эшләүләрен күрсәтеп үтте.

Доклад буенча фикер алышулар зур активлык белән үтте. Фикер алышуларда Карпушин, Козлов, Ахмеров, Филиппов, Ананьев, Федоров, Афанасьева һәм башка күп кенә иптәшләр чыгып сөйләделәр. Алар иптәш Бычковның докладын тагын да тулыландырдылар, партия сафларына кабул итү, яшь коммунистларны тәрбияләү эшләрен яхшырту турында конкрет такдимнәр бирделәр.

Киңәшмәдә ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Алемасов зур һәм тирән эчтәлекле речь белән чыкты.

Партактив ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы йомгаклары һәм шәһәр партоешмасының бурычлары турындагы доклад буенча тиешле карар кабул итеп үзенең эшен тәмамлады.

ВКП(б) РАЙКОМНАРЫНЫҢ ПЛЕНУМНАРЫНДА

БИЛӘР РАЙОНЫ

ВКП(б) ның Биләр район комитетының киңәйтелгән пленумы булды. Пленумда 68 кеше катнашты. Пленум партия Өлкә Комитетының VIII нче пленумы йомгаклары турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Федоровның докладын тыңлады. Фикер алышуларда 23 кеше чыгып сөйләде.

Иптәш Вәлиев (ВЛКСМ ның район комитеты) үзенең чыгышында, ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң Биләр партия оешмасы иң яхшы эшчеләр, колхозчылар һәм интеллигенция хисабына 47 процентка үскәнлеген, партиянең яңадан 12 башлангыч оешмасы һәм кандидатлар группалары төзелгәнлеген күрсәтте. Партия сафларының үсүе партиягә яңа алынганнарның идея ягыннан кораллануы һәм активлыгы үсүе белән бергә барды.

Иптәш Кәримев, районлагы күп кенә башлангыч партоешмаларның партиягә яңа алынганнар арасында начар эшләүләрен күрсәтеп үтте. ВКП(б) райкомы да яшь кандидатлар белән аз эшли.

Икенче мәсьәлә итеп, пленум кадрлар бүлегенең эше турында ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Вафинның докладын тикшерде.

ЛАИШ РАЙОНЫ

Партиянең башлангыч оешмалары секретарьларының һәм район партия активының катнашы белән, ВКП(б) ның Лаиш район комитеты пленумы булды. Пленум ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы йомгакларын, 1939 нчы елда районда партия сафларының үсеше һәм язгы чәчүгә хәзерлек турындагы мәсьәләләрне тикшерде.

ТАССР ның ХХ еллыгына хәзерлек

ЯРТЫ ЕЛЛЫК ПЛАННЫ 25 НЧЕ ИЮНЬГӘ ҮТӘРГӘ

Серго исемендәге завод коллективы ярты еллык планны Татарстан АССР ның 20 еллыгы көненә үтәү, данлыклы юбилейне яңа уңышлар белән каршылау турында йөкләмә алды. Заводның барлык цехларында, сменаларында һәм участкыларында социалистик ярышның яңа дулкыны күтәрелде.

Иптәш Сергеев бригадасы (иптәш Оборин цехы) норманы көн саен 270—300 процент итеп үти. Бригада эшләгән эшнең сыйфаты яхшы. Шәһәр советы депутаты стахановчы иптәш Вохонина ике станокта эшләүгә күчте һәм норманы 150 процент итеп үти. Башка стахановчылар да берничә станокта эшләүгә күчәләр.

(ТатТАСС).

ЯҢА ЙӨКЛӘМӘЛӘР

Язу машиналары заводының барлык цехларында һәм бригадаларында Татарстан республикасының ХХ еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен зур хәзерлек эшләре башланды. Шушы уңай белән цехларда һәм бригадаларда беседалар үткәрелә. Заводның стахановчылары һәм эшчеләре яңа йөкләмәләр алалар.

Механика һәм җыю цехлары ярты еллык планны 24 нче июнь көненә үтәү турында йөкләмә алдылар. Иптәш Иванова бригадасы январь ае планын 125 процент, иптәш Ратникова бригадасы 117 процент итеп үтәделәр. Цехның алдынгы стахановчылары Котлин, Шәрипов, Кандратьев, Блохин һәм Мансуров иптәшләр январь аенда планны 180—219 процент итеп үтәп, хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирделәр.

Ф. С.

Юдино депосының атаклы машинисты иптәш М. К. Крылов 1907 нче елдан бирле машинист булып эшли. Аның бер генә дә авариясе булганы юк. СССР Верховный Советы Президиумы указы буенча иптәш Крылов Ленин ордены белән бүләкләнде. РӘСЕМДӘ: паровозчылар цехының парторгы иптәш А. И. Афанасьев (сулда) иптәш Крылов белән беседа ясый.

В. Лужбин фотосы.
(ТатТАСС фотохроникасы).

ПРОИЗВОДСТВО КҮТӘРЕНКЕЛЕГЕ

4 нче номерлы тегү фабрикасы коллективы 1939 нчы ел планын срогыннан элек үтәп, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча шактый зур уңышларга иреште. Фабрика коллективы, үзенең яхшы эшләве өчен, җиңел промышленность наркоматының һәм тегүчеләр союзының күчмә кызыл байрагы белән бүләкләнде.

Татарстанның ХХ еллыгына хәзерлек уңае белән фабрикада социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте киң колач ала. Фабриканың барлык цехларында һәм бүлекләрендә социалистик ярыш договорлары яңартып төзелә. Кисү цехы коллективы шушы уңай белән яңа йөкләмәләр алды. Планны системалы рәвештә арттырып үтәү белән бергә, ярым фабрикатка, электр энергиясенә экономия ясарга һәм продукциянең үзенә төшү бәясен шактый киметергә булды. Хәзер фабрикада берьюлы берничә профессияне үзләштерү буенча да шактый зур эшләр эшләнде. Икенче группада эшләүче Әхмәтҗанова һәм Шамова иптәшләр ике процесста эшлиләр һәм норманы һәр вакыт арттырып үтиләр.

Цехларда политик-агитация эшләре шактый яхшырды. Партбюро тарафыннан билгеләнгән агитаторлар Татарстанның ХХ еллыгы уңае белән республикабызның үсешләре турында цехларда беседалар үткәрүгә хәзерләнәләр.

К. Х.

ЕЛГА БЕР МИЛЛИОН СУМ ЭКОНОМИЯ

Казан мех фабрикаларының эшчеләре һәм инженер-техник работниклары производствоны рационаллаштыру буенча үткән елны 342 такдим керттеләр. Болардан 110 такдим тормышка ашырылды, бер миллион сумнан артыграк экономия ясалды. Икенче мех фабрикасының чимал цехы начальнигы Маслов һәм Арзамацев иптәшләр сарык тиреләрен чистарту һәм юу өчен тизләтелгән метод такдим иттеләр. Бу такдим елга 121 мең сумнан күбрәк экономия бирә.

1 нче мех фабрикасында Серебрянников һәм Биншто иптәшләр сарык тиреләрен хром-бакыр составы белән буяу турында такдим керттеләр. Бу такдим буенча бер елга 45 мең сумнан артык экономия алына.

1939 нчы елда мехкомбинат дирекциясе алдынгы уйлап табучыларны бүләкләү өчен 35.535 мең сум акча тотты. Комбинатның рационаллаштыручылары һәм уйлап табучылары 1940 нчы елда 700 такдим кертеп, бер миллион ярым сум экономия ясауны йөкләмә итеп алдылар.

ДЕМОКРАТИК ФИНЛЯНДИЯ РЕСПУБЛИКАСЫН ЯКЛАУГА

Кызыл Армия частьләре Финляндия чиген үтүнең икенче көнендә үк инде, Финляндиядә чын хезмәтчел халык тавышы яңгырады. Илнең төрле өлешләрендә фин халкы үзенең изүчеләренә каршы восстание күтәрде, һәм 1939 нчы елның 1 нче декабрендә күп кенә сул партияләр һәм восстание күтәргән фин солдатлары вәкилләренең килешүләре буенча Финляндиядә яңа хөкүмәт—Отто Куусинен җитәкчелегендә Демократик Финляндия Республикасының Халык Хөкүмәте төзелде. Бу яңа хөкүмәт үзара ярдәмләшү һәм дуслык турында Советлар Союзы белән 2 нче декабрьдә договорга кул куйды. Бу договор Көнчыгыш һәм Төньяк-Көнчыгыш Европада ныклы тынычлык урнаштыра һәм СССР белән аңа дусларча карашта булган демократик Финляндия арасында тынычлык мөнәсәбәтләрен тулысынча тәэмин итә. Бөтен дөнья реакциясе һәм аның социал-демократик ялчылары бу договорның төзелүендә үзләренең империалистик планнарының җимерелүен күреп, СССР ның „агрессиясе“ турында, „Кызыл империализм“ һәм башкалар турында барлык көчләре белән акыра башладылар. Тормышның үзе тарафыннан фаш ителүче шушы барлык контрреволюцион акрынуларга, коткычкы яла ягуларга һәм ялганнарга каршы килеп, бөтен дөнья хезмәт ияләренең киң массасы Кызыл Армиянең Финляндиягә басып алу теләге белән түгел, бәлки фин халкын чит ил империализмы богавыннан азат итүче сыйфатында керүен торган саен ачыграк аңлый. Халык хөкүмәтенең чакыруы буенча Кызыл Армиянең Финляндиядә хәрәкәт итүе Советлар иленең Төньяк күршесенең бәйсезлеген, фин халкының тыныч хезмәтен, шулай ук социалистик дәүләт чикләренең куркынычсызлыгын тәэмин иткәнлеге бөтен дөнья хезмәт ияләренә торган саен ачыклана бара. Шуңа күрә дә дөньяның барлык илләрендәге хезмәт ияләре үзләренең җыелышларында, митингларында, төрле газеталарның редакцияләренә язган хатларында Советлар Союзының эзлекле һәм актив тынычлык политикасын бик яхшы дип табалар һәм Демократик Финляндия Республикасына һәм аның Халык Хөкүмәтенә үзләренең мәхәббәтләрен һәм котлауларын белдерәләр.

⁂

Москвада Совет — Финляндия сөйләшүләре барган чорда коммунистик партияләр Финляндиянең банкротлашкан политикаларының гадәттәгечә булмаган ныклык күрсәтүләренең сәбәпләрен, империалистик дәүләтләрнең планнарын—Финляндиядән СССР га каршы контрреволюцион көрәш плацдармы төзүгә юнәлдерелгән планнарын массага аңлаттылар. Барлык илләрдәге коммунистик партияләр хезмәтчел фин халкының азатлык көрәшен һәм аңа Кызыл Армия тарафыннан күрсәтелә торган ярдәмне гаять зур энтузиазм белән котладылар.

Англия коммунистик партиясе үзенең өндәмәсендә болай дип язды:

„Фин халкының үзенең реакцион җитәкчеләренә һәм илдә хөкем сөрүче чит ил банкирларына каршы азатлык көрәше уңышлы рәвештә киңәя. Совет хөкүмәтенең һәм Кызыл Армиянең ярдәме белән фин халкы банкирларны һәм илдә хуҗалык итүче чит ил милитаристларын куып җибәрер...“.

АКШ коммунистик партиясенең үзәк органы — „Дейли Уоркер“ газетасы Демократик Финляндия Республикасы иглан ителүнең икенче көнендә үк инде мәкалә басып чыгарды. Финляндиянең „җитәкчеләрен“ СССР га каршы дошманлык хәрәкәтенә котыртучы АКШ ның җитәкче даирәләрен бу мәкаләсендә газета болай дип фаш итте:

„Уолл-стритның көчләре Америка халкын сугыш упкынына этәрәләр... Америка халкы Советлар Союзы тарафыннан ясалган адымнарның кирәклеген һәм тулысынча гадел булуын бик җиңел аңлар“.

Швеция коммунистик партиясе үзенең үзәк органы „Ню Даг“ газетасы болай дип яза:

„Швециянең эшчеләр сыйнфы фин эшчеләренә карата кайнар мәхәббәт күрсәтә. Үз хөкүмәте тарафыннан ачлыкка, мөхтаҗлыкка, хокуксызлыкка һәм үлемгә дучар ителгән фин туганнарга — сыйныфташларга йөз меңнәрчә швед эшчеләре мәхәббәт белдерәләр. Швеция пролетарияты чын бәйсезлек өчен көрәштә фин халкына ярдәм кулын суза. Ләкин әгәр дә швед эшчеләре реакцион ак финнәрнең идарә итүче даирәләренең Советка каршы көрәшен яклаган булсалар иде, моның белән алар фин эшчеләренең үлем дошманнарына һәм палачларына ярдәм иткән булырлар иде һәм үзләренең сыйныфташ фин туганнарына дошман булган булырлар иде“.

Норвегия коммунистик партиясе дә киң күләмдә аңлату эше алып бара. Норвегия коммунистик партиясенең үзәк органы „Арбейдерен“ газетасы Финляндиядәге вакыйгалар уңае белән болай дип яза:

„Эшчеләр фин халкына аның дошманнарга каршы, Финляндиянең эксплоататорлар сыйнфына каршы көрәшенә актив ярдәм күрсәтүне таләп итәргә тиешләр. Норвегия эшчеләре бу көрәшкә барлык средстволар белән ярдәм итәләр, чөнки ул көрәш күп газаплар күргән фин халкы өчен тынычлык, азатлык, икмәк һәм демократия хакына алып барыла“.

Бельгия коммунистик партиясе үзенең үзәк газетасы тыелган булуга да, митинглар һәм җыелышлар тыелган булуга да карамастан, көрәшүче фин халкына һәм аңа ярдәмгә килгән героик Кызыл Армиягә теләктәшлек белдерү өчен барлык мөмкинлекләрдән файдалана. Бельгия компартиясенең генеральный секретаре иптәш Релеком парламентта речь белән чыкты. Бу речендә ул Рютинең Финляндия хөкүмәте дигән нәрсәсен фаш итте. Иптәш Релеком, Бельгиянең коммунистлары һәм пролетариилары Финляндиянең үзенең изүчеләренә—капиталистларга һәм алпавытларга каршы көрәшүче Халык Хөкүмәте ягында һәм фин халкы ягында торалар, дип белдерде. Бельгия компартиясе Финляндия коммунистик партиясе Үзәк Комитетына котлау җибәрде, шулай ук өндәмә басып чыгарды. Бу өндәмәдә ул Бельгиянең эшчеләрен фин халкына һәм аның Халык Хөкүмәтенә теләктәшлек күрсәтергә чакыра, реакционерларның яла ягу кампаниясенә җавап бирергә чакыра.

Италия коммунистик партиясе Финляндия компартиясе Үзәк Комитетына котлау җибәрде. Котлауда болай диелә:

„Италиянең хезмәтчел халкы фин эшчеләренә һәм крестьяннарына көрәштә ярдәм күрсәтүче данлыклы Кызыл Армияне котлый.

Италиянең хезмәтчел халкы Демократик Финляндия республикасы белән Советлар Союзы арасында төзелгән үзара ярдәмләшү һәм дуслык пактын Советлар Союзы тарафыннан үткәрелә торган туганлыкның, халыкларның милли азатлыгы һәм бәйсезлеге политикасының ачык мисале сыйфатында, Ленин—Сталин милли политикасының яңа җиңүе сыйфатында котлый, ул бөтен дөньядагы хезмәт ияләре массасына зур йогынты ясар“.

Франция, Голландия, Дания, Чили, Мексика, Швейцария, Люксембург һәм башка илләрнең коммунистик партияләре дә зур аңлату эше алып баралар. Сугыш уты кабызучылар тарафыннан таратыла торган ялганны һәм яла ягуны компартияләр фаш итәләр, фин халкының азатлык көрәшенең һәм Советлар Союзының эзлекле тынычлык политикасының халыкара пролетариатның көрәше өчен һәм гомуми тынычлык эше өчен гаять зур әһәмиятле булуын хезмәт ияләренең киң массасына аңлаталар.

Советлар Союзы белән һәм Финляндиянең Халык Хөкүмәте белән теләктәшлек кампаниясе Англиядә дә киң колач алды.

Демократик Финляндия Республикасы иглан ителү һәм Финляндия Халык Хөкүмәте төзелү турындагы хәбәр фин халкының үзе тарафыннан да, шулай ук Америка Кушма Штатларында һәм Канадада яшәүче финнәр тарафыннан да гаять зур энтузиазм белән каршы алынды (АКШ та 325 мең чамасы финнәр яши).

Европадагы империалистик сугыш нәтиҗәсендә килеп туган чиктән тыш катлаулы шартларга да карамастан, барлык капиталистик илләрдә прогрессив хәрәкәтне эзәрлекләүләр көчәюгә, алдынгы һәм демократик матбугатны тыюга да карамастан, фин халкының азатлык көрәше турындагы һәм турыдан-туры Совет чиге якынында чит ил империалистлары тарафыннан тудырылган куркынычлы сугыш учагын бетерү өчен Совет хөкүмәтенең приказы буенча чыгыш ясаган Кызыл Армиянең—азатлык армиясенең хәрәкәтләре турындагы чын барлык хезмәт ияләренең иң киң массаларына кадәр барып җитә. Барлык капиталистик илләрдә хезмәт ияләре империалистик буржуазиягә һәм аның социал-демократик ялчыларына каршы үзләренең тавышларын торган саен катырак күтәрәләр. Империалистик сугыш утын кабызучыларга каршы көрәштә хезмәт ияләре, эшчеләр сыйнфы эше өчен үзләрен турылыклы көрәшчеләр итеп таныткан коммунистик партияләр тирәсенә сафларын туплыйлар. Котырынучы капиталистик диңгез уртасында кыя таш булып торучы һәм халыкны үзенең азатлыгы өчен көрәшкә рухландыручы бөек һәм куәтле социализм иле тирәсенә хезмәт ияләре үзләренең сафларын туплыйлар.

Д. К.

ТӘҖРИБӘЛӘРНЕ УРТАКЛАШУ ӨЧЕН

Безнең кайбер тәҗрибәләребез



Югары иген уңышы өчен, ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү өчен көрәштә колхозларның хата - лабораторияләре гаять зур урын тоталар. Алар авыл хуҗалыгы фәненең казанышларын производство шартларында сынап карау буенча зур эш алып баралар һәм аларны турыдан-туры производствога кертә баралар.

Соңгы елларда безнең хата-лабораториябез тарафыннан да күп кенә тәҗрибәләр үткәрелде.

Безнең хата - лабораториябез уҗымнарны яз көне тырмалау һәм тукландыру буенча тәҗрибәләр үткәрде. Бу тәҗрибә уңышлы нәтиҗәләр бирде. Мәсәлән, без үткән елны тукландыру үткәрелмәгән гади участкыларда арышның һәр гектарыннан бары 7,15 центнер уңыш алсак, яз көне гектарына 20 тонна чермә кертеп тукландырган участкыларыбызның һәр гектарыннан 9,2 центнер уңыш алдык. Гектарына 6 тонна исәбеннән фекаль кертеп тырмаланган участкыларда 11,20 центнер уңыш чыкты. Гектарына 8 центнер исәбеннән тавык тизәге кертеп тырмаланган участкыларыбыз гектарыннан 13,8 центнер (гади участкылардагыга караганда 5,93 центнерга артыграк) уңыш бирделәр.

Кар тоту буенча да тәҗрибәләребез бар. Без моның буенча берничә вариантта тәҗрибә үткәрдек. Туңга сөрелгән, кар тотылмаган, шакмаклап чәчелгән участкыларда үткән елны гектарыннан 5,2 центнер уңыш чыкса, 50 сантиметр калынлыкта кар тотылган, шакмаклап чәчелгән участкыбызда гектарыннан 9,6 центнер уңыш чыкты. Бу, гади участкылардагыга караганда һәр гектардан 4,4 центнер өстәмә уңыш дигән сүз.

Мин быел сорт сынау эше белән дә шөгыльләнергә хәзерләнәм. Шулай ук безнең лабораториябез гектарыннан кимендә 40 центнер иген уңышы алуга ирешүне бурыч итеп куеп, 7 гектар мәйданда ефремовчылар тәҗрибәсен дә кулланырга уйлый.

Бу эшләрнең барысында да хата - лабораторияләргә авыл хуҗалыгы белгечләренең якыннан булышлык итүләре таләп ителә. Без шулай бергәләп эшләгәндә генә ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү турында иптәш Сталин тарафыннан куелган сугышчан заданиене тиз үтәрбез.

Моденов.

Лаиш районы „Путь Ленина" колхозы хата лаборатория мөдире.

Кок-сагыз кыйммәтле культура ул



Мин колхозда кок-сагыз культурасы үстерү звеносы башлыгы булып эшлим. Кок-сагыз яңа һәм кыйммәтле культура. Ул каучук эшләү өчен кирәк. Безнең илдә бу культура моңа кадәр чит илләрдән алына иде, хәзер үзебездә үстерелә. Безнең колхозда ике еллык кок-сагыз 3,8 гектар, ә минем звенода 1 гектар чәчелгән иде. Звенода 6 кеше эшләдек. Без бу культураны үсү чорында берничә тапкыр утадык һәм 2 тапкыр тукландырдык. Орлыкның өлгерүен һәр көнне күзәтеп тордык һәм орлыкны көненә 3—4 тапкыр җыеп алдык. Көненә 5,5 килограмм орлык җыйдык. Барсы 47 килограмм җыелды. Кок-сагыз орлыгын җыю планы 470 процент үтәлде.

Бу культураның тамырлары һәр гектардан 8 центнер җыеп алынды. Тамыр җыю планы 400 процент үтәлде.

Колхоз кок-сагыздан 21.103 сум доход алды. Планны арттырып үтәве өчен 4.478 сум премия алды.

1940 нчы елда кок-сагызны 15 гектар чәчәргә хәзерләнәбез. Без быел тагын да зуррак уңыш алу өчен көрәшәбез. Хәзер кок-сагызның бик кыйммәтле һәм зур доходлы культура икәнлеген яхшы беләбез. Татарстанда бу культураны чәчү мәйданын тагын да киңәйтергә кирәк.

Партиябезнең XVIII нче съезды каучук бирә торган культуралар продукциясен арттыруга зур игтибар бирергә кирәклекне күрсәтте. Без, колхозларның алдынгы вәкилләре, шундый кыйммәтле культураларны үстерү өстендә тагын да яхшырак эшлик, тарихи съезд күрсәтмәләрен большевикларча үтик.

Ибраһимова.

Октябрь районы, Нәриман исемендәге колхоз звеноводы.

Техник культураларга игтибарны көчәйтик

Элекке вакытта Кукмара районы колхозларында техника культураларына бөтенләй әһәмият бирелми иде. Партия һәм хөкүмәт тарафыннан кайгыртучанлык күрсәтелү нәтиҗәсендә, соңгы елларда техника культураларына игтибар бирү көчәйде һәм техника культуралары мәйданы шактый үсте.

1937 нче елга кадәр Сталин исемендәге колхозда техника культуралары, аерым алганда җитен культурасы, уңышны бик түбән биреп килде. 1937 нче елдан башлап безнең колхозда җитен уңышын күтәрүдә беренче борылыш ясалды. Мин шул елны техника культураларын өйрәнү буенча оештырылган махсус курска җибәрелдем. Курста уку миңа зур белем бирде. Шул елны мин агрономия чараларын дөрес үткәрү нәтиҗәсендә җитеннең һәр гектарыннан уртача 5 центнер сүс уңышы алуга ирештем. Тырышып эшләү нәтиҗәсендә, безнең звенобыз соңгы ике елда да Кукмара районында җитен уңышы буенча беренче урынны алды.

Без звенода җитен уңышын күтәрүгә ничек ирештек соң?

Без звенода җитен чәчелергә тиешле участкыларны көздән иртә срокларда, кимендә 18 сантиметр тирәнлеккә туңга сөреп калдырабыз. Язга чыккач та ул җирләрне тырмалыйбыз, туфракка минераль ашламалар кертәбез. 1939 нчы елда җитен җирләрен кали тозы белән һәм суперфосфат белән ашладык. Яз көне чәчүгә кадәр җирне ике тапкыр культивацияләдек һәм культивацияләү артыннан ук тырмаладык. Рәт араларын 9 сантиметр калдырып тезмә чәчү машинасы белән чәчтек.

Үткән елны җитен чәчкәннән соң ук кар яуды. Кар 5 көн эреми торды. Кар эрегәннән соң туфракның өсте кабыкланып катты. Мин бу кабыкны культиватор ярдәме белән бетердем. Мулчирование үткәрдем. Чүп үләннәрен җентекләп утадык. Беренче утау җитен 10 сантиметр биеклектә вакытта үткәрелде.

Үткән елны Кукмара районында барлык җитен чәчүлекләре һәлак булды дип әйтерлек. Ә менә безнең звенобыз, югарыда күрсәтелгән чараларны дөрес үткәрү нәтиҗәсендә, җитеннең һәр гектарыннан уртача 4 центнер сүс һәм ике центнер орлык уңышы алды.

Ишмухаметов.

Кукмара районы, Сталин исемендәге колхоз звеноводы.

Һәрбер колхозда балалар яслесе

Колхозларда балалар ясләләре булдыру колхозчы хатын-кызлар өчен дә һәм безнең барыбыз өчен дә зур политик әһәмиятле булган бер мәсьәлә булып тора. Республикабызда 1—2 яшьлек балалары булган 150—200 мең колхозчы хатын барлыгын искә алганда, колхозларда ясләләрнең никадәр әһәмиятле учреждение булулары тагын да ачыграк күренә.

Ясләләр колхозчы анага кырда тыныч һәм яхшы эшләүдә ярдәм итәргә тиешләр. Ләкин бездә бу эшнең торышы яхшы түгел. Колхозлардагы ясләләр 1939 нчы елда үз алларына куелган гаять зур бурычны яхшылап үти алмадылар. Биредә, иң беренче чиратта, Наркомздрав гаепле. Ләкин бу мәсьәләдә колхозларның да, авыл Советларының да тоткан урыннарын читләтеп үтәргә ярамый.

Бездә кайберәүләр ясләләрне күз буяу өчен генә ачалар. Алар ачылалар да, берничә көннән соң ябылалар. Арча районының Күпербаш авылында ясле бинасыннан бәрәңге яровойлаштыру өчен файдаланалар. Мамадыш районының „Большевик" совхозында ясле өчен төзелгән бинага орлык тутырганнар.

Без ясләләрне шулай төзергә тиешбез ки, алар колхозларның чираттагы бурычларына җавап бирсеннәр.

1940 нчы елның авыл хуҗалыгы планын тикшергән вакытта һәрбер гектардан 100 пот иген уңышы алу планын тикшергән һәм раслаган вакытта колхоз ясләләре турында онытырга ярамый. Чөнки бу учреждениеләрне дөрес оештырганда гына хатын-кызлар көченнән тулысынча һәм дөрес файдаланырга мөмкин.

Гинзбург.

Татарстан сәламәтлек саклау халык комиссары,

Агротехникадан тулысынча файдаланыйк

Партиябезнең XVIII нче съездында иптәш Андреев болай диде: „Безнең авыл хуҗалыгыбыз һәм игенчелегебез—дөньяда иң эре, иң механикалашкан икәнлеген исбат итеп торасы да юк. Ләкин ул шулай да табигать стихияләренә шактый дәрәҗәдә бәйле булып кала,—без моны танырга тиешбез. Һәр елны СССР ның теге яки бу өлешендә корылыктан, дымлылык һәм явым җитешмәгәнлектән, колхозлар һәм совхозлар йөз милионнарча пот ашлыкны һәм терлек азыгын югалталар".

Стихия—корылык безне түгел, ә бәлки, без аны җиңәрлек итеп коралланырга тиешбез. Хәзерге шартларда бу бик мөмкин.

Көньяк-көнчыгышның корылыклы районнарында ныклы уңышны тәэмин итүнең кирәклеге турында СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары моннан ике ел элек игълан ителгән иде. Бу карар Сталинчыл кайгыртучанлыкның иң гүзәл үрнәге. Һәм без корылыктан сакланып калырга түгел, ә киресенчә корылыкка каршы һөҗүм итәргә тиешбез. Без үз эшебезне нинди генә һава шартлары булуга да карамастан, югары иген уңышы алырлык итеп оештырырга тиешбез.



Ләкин нинди агротехника кулланырга кирәк? Агротехниканың иң беренче чиратта кулланырга тиеш булган чаралары: беренчедән—туңга сөрү. Иген уңышын күтәрү өчен тирән сөрү—ул, агротехниканың төп чарасы булуын инде һәр кем аңлый. Икенчесе—кар тоту. Бу турыда күп сөйләделәр. Бу чараны үткәрү күп средстволар таләп итми. Өченчесе—яровойлаштырылган орлык чәчү. Бу агротехника чараларын үткәргәндә иген уңышы тәэмин ителәчәк, билгеле.

1936 нчы ел, коры ел иде. Ул вакытта мин хата-лаборатория мөдире булып эшли идем. Шушы коры елны мин үз лабораториямдә берничә делянкада тәҗрибә үткәрдем. Мин бу делянкаларны гектарына 20 центнер исәбеннән тиресләдем, гектарга 2,5 центнер исәбеннән суперфосфат белән тукландырдым. Нәтиҗәдә, контроль участкылар һәрбер гектарга уртача 9 центнер уңыш бирсәләр, тәҗрибә участкылары уртача 14,5 центнер уңыш бирделәр.

1934 нче елны да мин бер тәҗрибә үткәргән идем. Биредә мин тавык тизәгенең көчен сынап карадым. Тавык тизәген башта чистарттым, аны вакладым. Аннан соң 6 йөк тизәкне басуга чыгарып, 20 сантиметр тирәнлегендә күмдердем. Тавык тизәге белән ашланган участкы гектарга 32 центнер уңыш бирде.

1936 нчы елны киндер буенча тәҗрибә үткәрдем.

Гектарга 36 тонна тирес кертү яхшы нәтиҗә бирде. Мин һәр гектардан 12 центнер киндер орлыгы һәм 14,5 центнер сүс алдым.

Иген уңышын тагын да күтәрик, югары агротехникадан тулысынча файдаланыйк. Колхозларны большевистик һәм колхозчыларны тәза тормышлы итү турында иптәш Сталин лозунгысын тулысынча тормышка үткәрик.

Яськин.

Мордовия АССР ның Җир Эшләре Халык Комиссары урынбасары.



Ленин исемендәге колхозның (Норлат районы) председателе, Татарстан авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе делегаты иптәш Х. Гайнуллин Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Баш Комитеты тарафыннан үз колхозына бүләк итеп бирелгән мотоцикл янында.

И. Галиев фотосы.

Ярышучылар

Авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсенең президиумы Татарстан, Чувашстан һәм Мордовия республикалары арасында төзеләчәк социалистик ярыш договоры проектының укылуын игълан итү белән, залда карандаш очлау, блокнотлар ачу башланды. Ләкин бу, очы сынган, яки сөрмәсе беткән карандашларны очлау түгел. Бу просто, болай да яхшы язарлык очлы карандашларны очлау. Тормышта шулай, кай чакларда, яки берәр кадерле кешене көткәндә яки нинди дә булса бер яңа эш башлау алдыннан әллә ничек дулкынланып аласың: тик торасы килми, нәрсә белән булса да шөгылльләнәсе килә. Залда утыручы делегатларның күпчелек өлешенең кирәкмәгәнгә карандаш очлаулары да менә шулай тормышта бик еш очрый торган, ләкин гадәттә без искәрә алмый торган гади бер күңел кузгалуы, „тынычсызлану" иде.

Шулай карандашлар очланды, блкнотлар ачылды һәм делегатлар өч республика арасында төзеләчәк ярыш договоры шартларын тыңларга керештеләр. Һәр кем беренче чиратта үзенә кагылган мәсьәлә белән кызыксына: тракторчылар ЧТЗ һәм ХТЗ тракторлары белән эшләү өчен куелган күрсәткечләрне блокнотка төртеп куялар, машинистлар исә аерым культураларны урып-җыю эшләре ничә көндә тәмам булырга тиешлекне хәтердә калдырырга омтылалар, кыскасы, зал „тыныч" түгел, юк, кая ул, „тыныч" булу! Бу бит бик күп пунктларны эченә алган договор проекты. Бу бит иптәш, сиңа да һәм миңа да кагыла дигәндәй, колхоз төзелешенең бөтен тармакларын эченә ала.

Проект укылып бетү белән сөйләргә теләп әле тегеннән, әле моннан кул күтәрәләр. Ярыш шартлары бик үк җиңел түгел, бүрек белән бәреп кенә беренчелекне алып булмаячакны бик нык аңлыйлар. Шуның өчен дә кузаклы культураларны җыеп алуны договор проектында күрсәтелгәнчә 5—6 көндә тәмам итү срогын кайберәүләрнең „3 көн эчендә тәмам итәргә" дигән такдимнәрен делегатлар бик җидди рәвештә тикшерделәр һәм бу пунктны алай үзгәртүне мәсьәләгә җиңел төс бирү дип карадылар. Мондый мөһим эшкә башлаганда—ярышка чыкканда кем нәрсә әйтсә, шуңар риза булып утырырга ярыймы соң. Шуның өчен делегатлар договор проектының кайбер пунктларын кайтып-кайтып кабат укыталар, аларны кабат тыңлыйлар. Делегатлардан бер иптәш торып нинди орлык чәчү турындагы шартлар язылган пунктны яңадан укып чыгуны таләп итә:

— Сортлы орлык чәчәргә диелгәнме, әллә сортланган орлык чәчәргә диелгәнме? Аларның аермасы—җир белән күк арасы кебек, иптәшләр,—ди. Һәм зал бу пунктны яңадан тыңлый:

— „Сортлы", диелгән, „сортлы",—дип кабатлап куялар алар.

— Шунда ук Саба районы делегациясе исеменнән президиумга бирелгән язу укыла. Алар договорга һәрбер колхозда тирес саклый торган аерым бер урын булдыруны кертергә такдим итәләр. Киңәшмә бу өстәмәне бик яхшы каршы ала.

Озак тикшерелгәннән соң ярыш договоры киңәшмә тарафыннан кул чабулар астында кабул ителә.

Көн тәртибендәге мәсьәләләр каралып беткәч, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе Комитеты тарафыннан бүләкләнгән колхозларның исемлеге укылып чыккач һәм мөраҗәгать кабул ителгәч, киңәшмә ябыла. Делегатлар инде таралалар. Бер төркем халык Столбище районының „Память Ленина" колхозының хата-лаборатория мөдире Г. Полянкин иптәшне сырып алганнар. Колхозны яшелчә уңышы белән күмгән бу мастер киңәшмә трибунасына басып, үзенең тәҗрибәләрен бер кат сөйләгән иде инде. Күрәсең, халыкның аны тагын да тыңлыйсы килә һәм аны тыңламаслык та түгел. 1939 нчы елда дәүләткә 360 тонна яшелчә тапшырып, копперациягә 50 тонна сатып, һәрбер хезмәт көненә, 24,5 килограмм бәрәңге, яшелчә бүлүгә ирешкән „Память Ленина" колхозының эшенә һәр кем кызыгыр. Аннан бер юлы 3—4 кеше сорый:

— Кара әле, син 70 килограмм сортлы бәрәңгене 3 ел эчендә 96 тоннага җиткердем дисең. Ничек алай булды соң ул?

— Полянкин бер дә ашыкмыйча куллары белән һәр төрле хәрәкәтләр ясап, сөйли башлый:

— Без колхозны сортлы бәрәңге орлыгы белән мөмкин кадәр тизрәк тәэмин итү өчен менә мондый метод кулландык. 1937 нче ел иде. 70 килограмм „№ 611" сортлы бәрәңгене 20 нче мартта яровойлаштырырга салдык. Аны 55 көн вакыт 18 градус җылылыклы караңгы бинада тоттык. Шушы бәрәңгеләрнең шытып чыккан бәбәнәкләре 4—5 сантиметрга җиткәч, аларны барсы 3 тапкыр, ягни бер бәрәңгедән 15 бәбәнәк сынды рып алып, парникка утырттык. Парникны да шулай ук караңгы итеп тоттык. Парникта бәбәнәкләрнең озынлыклары 20 сантиметрга җиткәч, аларның төпләренә су сибеп җиргә күчердек. 3 тапкыр утадык һәм төпләдек. Менә шулай тиз үрчетү юлы белән утыртылган шул елгы бәрәңге орлыгы 2 центнер булды. 1938 нче елда әлеге 2 центнер орлыкны тагын шулай тиз үрчетү юлы белән ягни 36 мең рассадага җиткереп утырттык. Ул елны 2 центнер бәрәңгедән 100 центнер, димәк 1 центнерга 50 центнер уңыш алдык. 1939 нчы елда инде без бәрәңге орлыгын болай тиз үрчетү ысулын кулланмадык. Чөнки безнең инде орлык болай да җитәрлек булды.

— Ә җирегез нинди сезнең?—дип сорыйлар аннан.

— Җир—җир инде, комсу балчыксыл туфрактан тора. Аны көз көне 22 сантиметр тирәнлектә туңга сөреп калдырдык. Элекке елны кәбестә чәчелгән иде ул җиргә. Язга чыккач бик иртә тырмаладык. Һәм беренче тапкыр кабатлап сөргән чакта гектар саен 60 тонна хисабына тирес, 9 центнер көл, 3,5 центнер кали тозы һәм 3 центнер суперфосфат керттек. Икенче тапкыр сөргәндә тырма астына 3,5 центнер сульфат аммоние кертеп калдырдык. Менә шулай эшләдек без бәрәңге җирен.

— Бер хезмәт көненә 24,5 килограмм яшелчә бүлдек, дисеңме?—дип сүз кузгата икенче бер делегат.

— Әйе, 24,5 килограмм. Шуннан кәбестә—8,5 килограмм, бәрәңге—4,5 килограмм, кыяр—2, кишер—1,5, чөгендер—5,5 килограмм, ә калганнары суган, помидор кебек яшелчәләр. Боларның бөтенесен уртача базар бәясе белән исәпләсәң, безнең һәрбер хезмәт көнебез 42 сум тора. Безнең арада, хезмәт көненә 1.408 пот яшелчә алган стахановчы Защитин кебек кешеләр бар. Минем үземә дә кәбестәне генә дә 18 йөк китерделәр. Бәрәңгене дә шулай берничә олау белән китерделәр. Безнең хезмәт көннәренә бүленгән бәрәңгеләрнең һәр берсе бер кадак тарта,—ди.

Тыңлаучылар аптырап калалар:

— Бер кадак?

— Әйе, мин әле киметеп әйтәм, арада яртышар кило тарткан бәрәңгеләр дә очрый. Сез аңа бер дә шак катмагыз. Вактында утасаң, вактында төпләсәң бәрәңге бик уңа ул. Ә менә быел—1940 нчы елда без гектар саен 700 центнер бәрәңге, 1.000 центнер соңгы кәбестә, 450 центнер кыяр, 300 центнер суган, 500 центнер кишер алуны бурыч итеп куйдык.

Сөйләшү һаман дәвам итә.

— Сезнең җирегез ничә гектар?

— Бөртекле культуралар чәчү мәйданы 335 гектар, яшелчә чәчү мәйданы—75 гектар, бәрәңге—92 гектар.

— Күп тә түгел икән.

— Әлбәттә, күп түгел.

— Ә алган уңышыгыз күп.

— Анысы да күп түгел, күпне алу алда әле безнең. Гектар саен 1.000 центнер бәрәңге алуга ирешергә уйлыйбыз. Бәрәңге бит ул бик күп нәрсәләргә ярый. Аннан крахмал да ясыйлар, каучук та ясыйлар, спирт та чыгаралар, барсына да ярый ул. Шуның өчен бик уңдырырга, бик күп алырга кирәк аны.

Делегатлар:

— Шулай итәсе иде шул,—дип аның белән бергә Менжинский исемендәге клубтан чыгалар һәм байтак вакытлар аннан аерыла алмыйча торалар.

Казанның Ирек мәйданында делегатлар кайсы кая үзләренең торак урыннарына таралалар. Полянкинның үзенең дә делегатлардан аерыласы килми:

— Мин „Совет" гостиницасында, 77 нче номерда. Әйдәгез, иптәшләр, кемнәр минем якка кайта, бергә сөйләшеп кайтырбыз,—ди.

Берничә кеше аңа ияреп китә.

Ә бит, чынлап та, аңа иярсәң дә ярый!

Гариф Галиев.

Чит илләрдә

Ак Финляндиядәге хәл турында Швеция матбугаты

СТОКҺОЛЬМ, 3 февраль. (ТАСС). „Афтонбладет“ газетасы моннан берничә көн элек Американың хәрби хәбәрчесе Роберт Лоуның Маннергейм адъютанты белән беседасын басып чыгарды. Лоуның, — Финляндия озакка чыдармы, дигән соравына адъютант түбәндәге анекдот белән җавап биргән: бер америкалы гаять биек йорттан егылып төшеп бара икән. 20 нче этаж турысыннан төшкән вакытта ул тәрәзә аркылы үзенең куркынган иптәшен күргән. Аны тынычландыру өчен, ул: „Хәзергә барсы да яхшы бара әле!“ дип кычкырган.

Адъютант үзенең сүзләрен, — Финляндиянең хәле егылып төшеп баручы америкалының хәленә охшый, дип тәмам иткән.

Чит илләрдә ак финнәрнең вәкилләре, шулай ук Швеция матбугаты, Маннергеймга ашыгыч рәвештә ярдәм күрсәтергә бөтен дөньяны чакыралар.

Финляндиянең Париждагы илчесе 31 нче январьда Англия һәм Америка газеталарының хәбәрчеләренә болай дип белдергән: „Әгәр дә хәзер үк ярдәм алмасак, без—һәлак булуга дучар. Могҗизалар булган, ләкин аларның чиксез дәрәҗәдә кабатлануларын көтәргә ярамый“.

Финляндиянең „Суомен социалидемократти“ газетасы моннан 3 көн генә элек ак финнәргә ярдәм күрсәтү турында һәм беренче чиратта зур күләмдә сугыш ярдәме күрсәтү турында күңел болгаткыч дәрәҗәдә акырды. Газета болай дип язды: „Мораль булышлык үзебезнекеннән артык булган көч тарафыннан безгә ясала торган яраларны дәвалый гына ала. Ләкин, ул көчне җимерү өчен бу булышлык кына җитәрлек түгел“.

Ак фин властьлары Скандинавия илләренә, Көнбатыш Европа һәм Америка илләренә күп санда агитаторлар җибәрәләр. Ак фин сеймының члены—биредә җитәрлек дәрәҗәдә билгеле булган һәм Швециянең буржуаз даирәләре белән багланышта булган Фрич Швециядә гастрольдә йөри. Фрич үз чыгышларының берсендә,—бөтен фин армиясе, үзенең резервларын бетергәннән соң, тулысынча көчсезләнү алдында тора, дип күрсәтә. Фрич болай ди: „Без беренче чиратта гаскәрләребезне алмаштыру өчен шартлар тудырырга һәм безнең солдатларга кешегә хас булмаган шушы кискен хәлдән чыгу өчен һич булмаганда бер атна ял вакты бирергә тиешбез. Билгеле, безне берничә мең кеше генә канәгатләндерми“.

Маннергейм өере вәкилләре инде „доброволецлар“ җибәрүне таләп итү белән генә чикләнмиләр. Алар: „Арган һәм көчле рәвештә таркалган частьләрнең барсын да булмаса да, һәр хәлдә күпчелеген алмаштыра ала торган чын зур гвардиягә Финляндия мохтаҗ“ дип белдерәләр.

Швеция газеталарының моңа кадәр бары тик ак финнәрнең җиңүләре турында гына язып килгән хәбәрчеләре кинәт бер тавыштан фин армиясенең арганлыгы турында кычкырырга керештеләр. Хәтта, „Нюа даглигт алеханда“ дигән реакцион газетаның ак, финнәргә үзенең мәхәббәт күрсәтүе белән бик атаклы булган сотрудникы Григгс тарафыннан чыгарылган мәкаләне ярдәм сорап ялвару диюдән башка нәрсә дип әйтеп булмый. Ул: „Фин армиясе йокысын туйдыру һәм ял итү мөмкинлеген хәзер үк алырга тиеш, юкса һәлакәт килүе мөмкин“ дип яза.

„Сюдсвенска дагбладет снельпостен“ дигән провинциаль газетаның төньяк фронтны әйләнеп чыккан хәбәрчесе, ак фин гаскәрләре арасында „нерваларның моңа кадәр булмаган дәрәҗәдә киеренке булганлыгын“ һәм бу киеренкелекнең котылгысыз рәвештә шартлауга алып киләчәген күрсәтә. Шул ук хәбәрче фронтовиклар белән тылда яшәүчеләр арасында кискен мөнәсәбәтләрне характерлый торган фактлар турында хәбәр итә.

„Свенска дагбладет“ газетасының хәбәрчесе, ак финляндиядәге хәл турында язып, гәрчә хәзер инде бер могҗизалар гына җитәрлек түгел дип санаса да, бөтен ышанычны могҗизага баглый.

„Дагенс нюхетер“ газетасы да үзенең йомгак ясап язган баш мәкаләсендә ак финнәр өчен шатлыклы булудан бик ерак торган шундый ук нәтиҗәләргә килә.

Барлык газеталар ак Финляндиядәге кискен хәл турында булган хәбәрләрне ак финнәргә хәзер үк һәм киң рәвештә ярдәм күрсәтү теләге белән агитация алып бару өчен файдаланалар. „Дагенс нюхетер“ газетасы, „бөек державаларның ярдәм оештыруны бик үк ашыктырмаулары“ кызганыч хәл, дип күрсәтеп үтәргә мәҗбүр. Газета, „Алар бу ярдәмне вагдә итүгә саранланмадылар“, ди. „АКШ тагы политик даирәләрнең үз-үзләрен гаҗәп рәвештә тотулары аеруча зур тынычсызлык тудырды. Аннан килгән беренче хәбәрләргә караганда кредит алуны тизрәк булыр һәм хәзер вагдә итүләренә караганда күбрәк булыр дип көтәргә мөмкин иде“.

Швеция матбугаты Финляндиянең эчке хәле турында бер сүз дә дәшмәүне дәвам иттерә. Бары тик „Дагенс нюхетер“ газетасы гына күптән түгел ак фин „министрләреннән“ берсе белән булган беседаны басып чыгарды. „Министр“ промышленностьның, транспортның һәм судноләр йөртү эшенең чиктән тыш авыр хәлдә булуын күрсәткән. Заводларның күбесенә эвакуация ясалган. Ак финнәрнең Стокһольмдә булган социаль тәэминат „министре“ Фагерхольм, эшчеләрнең армиягә алынганлыкларын, пароходларның чит ил портларында үзләренә урнашу урны эзләүләрен, тимер юлларның зур өзеклекләр белән эшләүләрен, телеграф һәм телефон элемтәсенең бозылганлыгын белдергән.

СТОКҺОЛЬМ, 3 февраль. (ТАСС). Швециянең „Дагенс нюхетер“ газетасы, Парижда Англия һәм Америка журналистлары өчен булган аш мәҗлесендә Финляндия илчесе Хольмның: „Әгәр дә хәзер үк ярдәм алмасак, без—һәлакәткә дучар“ дип белдерүе турында Гавас агентлыгының телеграммасын басып чыгарды.

АК ФИНЛЯНДИЯДӘГЕ ХӘЛ ТУРЫНДА АМЕРИКА ГАЗЕТАСЫ

НЬЮ-ЙОРК, 3 февраль. (ТАСС). „Чикаго дейли ньюс“ газетасы, һавада совет авиациясенең хөкем сөрүе һәм „бөтен артыклыкның совет гаскәрләре ягында булуы“ турында хәбәр итә. Маннергейм цензурасы сугыш операцияләренең чын барышын һәм фин гаскәрләренең югалтуларын чит ил матбугатыннан яшерә. Газета, якын вакыт эчендә Маннергейм армиясенең тар-мар ителүе котылгысыз, дип күрсәтә.



Сугышны „тартучылар“ һәм „этүчеләр“.
В. Лисевич темасы буенча И. Миксонов рәсме (ТАСС фото-клишесе).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Үзәк Кытайда

Хубэй провинциясенең үзәк өлешендә, бик күп кар яуган булуга карамастан, Цзиншань белән Чжунсян арасындагы шоссе юлыннан төньякта көчле сугышлар бара. Кытайлар, 29 нчы январьда японнарның атакаларын кире кайтарып, икенче көнне кич белән японнарның позицияләренә үзләре һөҗүм башладылар һәм Цзиншань белән Чжунсян арасында японнарның коммуникацияләрен өзеләр. Хәрби чыганаклардан алынган маглүматларга караганда, японнар үзләренең базаларыннан аерылу куркынычы астында бу районда һөҗүмнәрен туктатсалар кирәк, дип уйлыйлар.

Кытай партизаннары Шанхай, Ханчжоу, Сучжоу һәм Цзясин районнарында японнарга зур күләмдә материаль зарар китерүне дәвам иттерәләр. Хәзер, 10 нчы январьда партизаннарның Цзясиндә япон складын яндырганлыклары маглүм булды. Складта 6 мең банкы бензин, 4 мең моток тимер чыбык, 10 йөк автомобиле һәм күп санда башка төрле сугыш кирәк-яраклары булган. 12 нче январьда партизаннар шунда ук японнарның икенче хәрби складларын яндырганнар. Барлык зарар кытай доллары белән берничә миллион доллар исәпләнә.

Көньяк Кытайда

Японнарның зур сандагы көчләре 2 нче февральдә Биньянга (Наньниннан төньяк-көнчыгышта) үтеп керергә маташтылар, ләкин кытай гаскәрләре тарафыннан чолганып алындылар. Кытай гаскәрләре японнарны Шипудан (Наньниннан 12 километр көнбатышта) кысрыклап чыгардылар.

Гуандун провинциясенең көнчыгыш өлешендә японнарның меңгә якын кешедән торган отряды 31 нче январьда Уканга (Чаочжоу белән Сватоу арасындагы ярты юлда) атака ясады. Каты сугыштан соң японнар Аньбуга таба чигендерелделәр. Японнар 300 кешеләрен югалттылар.

Кытайларның Хайнань атавында калган гаскәрләре японнарга каршы көрәш алып баруны туктатмыйлар. Бу гаскәрләр Майкоу белән Ваньлинны тоташтыра торган шоссе юлын һәр вакыт куркыныч астында тоталар.

Төньяк Кытайда

Суйюань провинциясендә Баотоу районында каты сугышлар дәвам итә. Биредә япон гаскәрләре авиация ярдәме белән хәрәкәт итәләр.

❖

1 нче февральдә японнарның берничә самолеты, Франция Һинд-Кытае чигеннән 83 километрдагы Ханой-Куньмин тимер юлын бомбага тоттылар. Берничә бомба Һинд-Кытайдан Кытайга бара торган пассажир поездына ташланды. Үлүчеләр һәм яраланучылар бар. Японнар бу юлдагы күперне җимерделәр. 2 нче февральдә биредә хәрәкәт яңадан урнаштырылды.

„Кызыл Шәрык“ заводының эшчеләр һәм хезмәткәрләр коллективы Татарстан АССР Наркомпищепром халык комиссары урынбасары иптәш А. А. Сечинга һәм туганнарына, аның туганы

НИКОЛАЙ АРИСТАРХОВИЧ СЕЧИН

ның вакытсыз үлүе уңае белән, кайгы уртаклашу белдерә.

Главхимсбытның Горький өлкәара конторасының Казан базасы белдерә:

Наркомхимпромның приказы нигезендә

„СОЮЗЛАБОРРЕАКТИВ“ НЫҢ КАЗАН МАГАЗИНЫ ЭШЕН ТУКТАТТЫ

Магазинның барлык функцияләре, шулай ук хокуклары һәм үтәлергә тиешле бурычлары Главхимсбытның 1940 нчы ел, 1 нче январьдан яңа оештырылган Казан базасына күчерелде. Базаның адресы: Казан, Чернышевский урамы, 2 (элекке Союзлабbooреактив бинасы) Телефон 4—24. Дәүләт Банкысының Татарстан Республика Конторасында расчетлар счеты № 176006. 213—2—1

Казан шәһәрендәге дәвалау учреждениеләре һәм барлык граждannар игтибарына!

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ СТАНЦИЯСЕ 5 нче номер шәһәр больницасы бинасына (телефоннар: 24—31 һәм 2—91), ә СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ШӘҺӘР БҮЛЕГЕ ашыгыч ярдәм станциясе бинасына (Киров урамы, 52, телефоннар: 10—23 һәм 10—24) КҮЧЕРЕЛДЕЛӘР.

Горздравотдел. 222—1

Казандагы 1 һәм 2 нче номер нефтебазалары

шушы ел, 1 нче февральдән бергә кушылдылар һәм яңа база

„Главнефтесбыт Татарстан Республика конторасының нефть бирү-күчерү Казан нефтебазасы

дип исемләнде.

Базаның адресы: Зур Ямашев урамы, 2. Телефон 36—70.

219—1 „Главнефтесбыт“ның Татарстан конторасы.

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫ ЮДИНО СТАНЦИЯСЕ ФЗУ МӘКТӘБЕ

паровозларга һәм вагоннарга ремонт ясаучы слесарьлар хәзерләү буенча

УКУЧЫЛАР АЛА

Мәктәпкә 15 тән 18 гә кадәр яшьтәге һәм тулы булмаган урта мәктәпне, яисә урта мәктәпнең 7 классын тәгәлләгән үсмерләр алыналар.

Мәктәпкә керүчеләр математикадан, рус теленнән һәм физикадан сынаулар үтәләр.

Гариза белән бергә, керүченең тулы булмаган урта мәктәпне яисә тулы урта мәктәпнең 7 классын тәгәлләве турында документ, яше турында белешмә һәм дәүләт учреждениесе тарафыннан раслаңга 3 фотокарточка бирелергә тиеш. Болардан тыш паспорт күрсәтелә.

Сынаулар шушы ел, 20 нче февральдән 25 нче февральгә кадәр үткәрелә, ә укулар шушы ел, 1 нче марттан башлана.

Мәктәпкә алынганнарга гомуми нигездә стипендия бирелә. Тору урны кирәк булган укучыларга тулай торакта урын да бирелә. Адрес: Казан тимер юлы. Юдино станциясе, ФЗУ мәктәбе. 206—1

ТАТАРСТАН АССР ФИНАНС ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ БЕЛДЕРӘ:

СССР Совнаркомының 1935 нче ел, 13 нче май карары һәм СССР Финанс Халык Комиссариатының 1939 нчы ел, 29 нчы декабрьдә чыгарган 830-169 нчы номерлы һәм 1940 нчы ел, 11 нче январьда чыгарган 22-7 нче номерлы күрсәтмәләре нигезендә, Татарстан АССР территориясендәге барлык учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре үзләренең 1940 нчы ел өчен расланган штатларын, ставкаларын һәм хезмәт хакы фондларын 1940 нчы ел, 1 нче июньгә кадәр тиешле финанс органнарында теркәтергә тиешләр.

Төзелеш, монтаж оешмаларының (трестлар, управлениеләр, конторалар) һәм эшләрен хуҗалык юлы белән алып баручы төзелешләрнең җитәкчеләре үзләренең штатларын шушы ел, 1 нче мартка кадәр теркәтергә, ә подрядный юл белән эш алып баручы төзелешләрнең, шулай ук проект һәм геолого-разведка оешмаларының җитәкчеләре үзләренең штатларын шушы ел, 15 нче апрельгә кадәр теркәтергә тиешләр.

Күрсәтелгән сроклар үткәннән соң Дәүләт Банкысы органнары хезмәт хакы түләү өчен кирәкле сумаларны бары 1940 нчы елда штатларын теркәтү турында бирелгән регистрация карточкасын күрсәтү буенча гына бирәчәк. ТАТНАРКОМФИН.

114—2—1

Яшеллек төзелешенең Казан тресты—Горзеленострой

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм частный кешеләрнең ишек алларын яшелләндерү буенча барлык кирәкле эшләрне үтәү өчен

ЗАКАЗЛАР АЛА ҺӘМ ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ

Трестның питомнигыннан декоратив материаллар, җимеш һәм җиләк үсентеләре (агачлар һәм куаклыклар) алырга мөмкин. Трестның адресы: Казан, Лобачевский урамы, 5. Телефон 44—25, Питомникның адресе: Казан, Оренбург тракты (элекке Каргопольский казармаларга каршы). Телефон: 2—81. 156—2—1

„ТРАНСЭНЕРГОКАДР“ НЫҢ

КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ

производстводан аерыйча укытып, 3 нче класс шоферлардан II һәм I нче класс шоферлар хәзерләү буенча шушы ел 10 нчы — февральдән —

КУРСЛАР АЧА

Курсларга предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алына. Казан, Банк урамы, 15. Телефон 38—52. 176—2—1

Казан Ветеринария техникумы студентларын урнаштыру өчен

БҮЛМӘЛӘР ҺӘМ ПОЧМАК — УРЫННАР КИРӘК —

Тәкъдимнәр өчен адрес: Телеграф тыкрыгы, 6-9. Телефон 24—44. 214—3—1

Архитектура-Планлаштыру — мастерскаясы —

(Чернышевский урамы 1, өченче кат, 36 нчы бүлмә)

китайский тушь, Рихтерский һәм башка төрле готовальнялар, шулай ук архитектура буенча китаплар һәм журналлар САТЫП АЛА. Бәяләре килешү буенча. 221—3—1

КИРӘК:

Камил Якуб исемендәге китап фабрикасына ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, ЭКОНОМИСТ-ПЛАНОВИК һәм СЧЕТ РАБОТНИКЛАРЫ. Казан, Бауман урамы, 19, Матбугат йорты ишек алдында. Кадрлар бүлегенә килергә. 209—2—1

Даими эшкә МЕЖРАЙМЕХАНИКЛАР, ТЕПЛОТЕХНИКЛАР, ПРАКТИК СТАЖЛЫ МЕХАНИКЛАР һәм МЕХАНИК-МАШИНИСТЛАР. Казанда эшләү өчен БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОРЛАР һәм районнарда эшләү өчен БАШ БУХГАЛТЕРЛАР. Центрозаготзерно Татарстан Республика конторасының кадрлар бүлегенә килергә. Ухтомский урамы, 11/16. Телефон 36—48. 224—2—1

Архитектура-Планлаштыру мастерскаясына даими эшкә НОРМАЛАУЧЫ-ПЛАНОВИК. Казан, Чернышевский урамы, 1, өченче кат, 36 нчы бүлмә. 220—3—1

Татарстан АССР НКВД ның хезмәт колонияләре бүлегенә ПРОИЗВОДСТВОЧЫ ИНЖЕНЕР, БАШ БУХГАЛТЕРЛАР, ТОВАР ЖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР һәм ХӘРБИЛӘШТЕРЕЛГӘН ОХРАННИКЛАР. Казан, Чернышевский урамы, 12/20, кадрлар бүлеге. 215—3—1

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

5 нче февральдә

КЫЮ КЫЗЛАР

Талон 108.

6 нчы февральдә көндез 12 сәгатьтә

КҮЗЛӘР (талон 109)

кич **КЫЮ КЫЗЛАР** (талон 110).

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

5 нче һәм 6 нчы февральдә кич

МАСКАРАД

Талон бүген 93.

6 нчы февральдә көндез

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Иртәгә талоннар: көндез 9 һәм кич 94.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

БҮГЕН ҺӘМ ҺӘР КӨН

Москва 4 нче труппасының — соңгы гастрольләре —

ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ, РСФСР ның атказанган артисты орденлы

М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик — труппасы белән —

6 нчы февральдә көндез 1 сәгатьтә

М. ЗОЛЛО

катнашы белән зур цирк уены.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ЦИРК
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	БӨЕК БҮЛӘК
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ТАЙГА ЕРАКЛЫКЛАРЫНДА
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез ФЕДЬКА Кич ТРАКТОРЧЫЛАР. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (2 нче сериясе)
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ

КОМПОЗИТОРЛАР СОЮЗЫН ТӨЗҮ АЛДЫННАН

Татарстан композиторларының союзын төзүгә хәзерлек эшләре тәмамланды, хәзер бурыч чын-чынлап эшкә керешүдән гыйбарәт. Шуның өчен дә бүген союзның алдында торган кайбер бурычларга, беренче чиратта эшләнергә тиешле эшләргә тукталып, аларны конкрет рәвештә билгеләп китү артык булмас.

Татарстан композиторларының тиздән җыелачак киңәшмәсе композиторлар союзының составы турында ачык бер караш тудырыр дип ышанып, без биредә күбрәк урынны һәм игтибарны иҗад мәсьәләләренә бирәбез. Чөнки иҗад мәсьәләләре союзның эшендә үзәк урынны алып торырга тиешләр.

Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик сәнгат тудыру эшендә Татарстанның музыка культурасы искә алырлык уңышларга иреште. Бу уңышлар ныгытылырга һәм киләчәктә яңа уңышларга ирешелергә тиеш.

Опера тудыру өлкәсендә булган эш татар композиторлары эшендә нигез булып торды һәм музыка сәнгатенең башка тармаклары әнә шул нигездә үстеләр. Тик музыка жанрлары бер опера белән генә чикләнмиләр. Опера тудыруда булган уңышларны ныгыту белән бергә, киләчәктә без симфония, камера музыкасы, җыр һәм хор жанрларына да нык игтибар юнәлдерергә тиеш булырбыз. Балет жанры бездә, соңгы көннәргә чаклы дип әйтерлек, ятим булып бер читтә калып килде. Аңа җитәрлек игтибар бирелмәде. Беренче татар балетын тудыруда ясалган уңышлы адым („Шүрәле“ балеты, композитор Фәрид Яруллин музыкасы, шагыйрь Әхмәт Фәйзи либреттосы) татар композиторларының бу эштә дә гаять зур мөмкинлекләре булуын күрсәтте.

Драма һәм балалар театрларында эшләүче композиторлар да үзләренә нык күзәтчелек һәм җитәкчелек итүне сорыйлар. Драма театрларында музыка эшен алып бару аеруча читен һәм катлаулы эш. Үкенечкә каршы, кайбер хәлләрдә бу җаваплылыкны төшенеп җитмәү фактларын да очратырга туры килгәли. (Моның өчен Татар Дәүләт Академия театрында куелган „Гәепсездән Гәеплеләр“ спектакленең музыка оформлениесен искә төшерү дә бик җитә). Әнә шул җаваплылыктан куркып булса кирәк, кайбер вакытларда театрлар, пьеса үзе музыканы сорап торса да, музыкаль оформлениедән качарга, спектакльдән музыканы бөтенләй „куып чыгарырга“ маташалар.

Шулай ук яшь композиторлар тәрбияләп үстерү эше дә композиторлар союзының игтибар үзәгендә торырга тиеш.

Композиторларның белем һәм культура дәрәҗәләрен өзлексез рәвештә күтәрү, аларны белемнәрнең белеме булган марксизм-ленинизм таглиматы белән коралландыру союзның принципиаль бурычларыннан берсе һәм иң мөһиме булып тора. Композиторларның профессиональ белемнәрен һәм гомуми белем дәрәҗәләрен күтәрү өчен без үзебездә булган көчләр белән барлык чараларны да үткәрә алабыз, моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Иҗад тәҗрибәләрен системалы рәвештә уртаклашу, киң совет җәмагатчелеге алдында иҗад имтиханнары уздыру, музыка сәнгатенең мөһим мәсьәләләрен киң җәмагатчелек белән берлектә тикшереп, бергә хәл кылу—менә бу мәсьәләләр союз алдында торган һәм аның көн тәртибенә керергә тиешле булган практик чаралар.

Музыка культурасын үстерү, киңәйтү, музыканы пропагандалау, филармония, радио комитет һәм башка шундый учреждениеләр белән элемтә алып бару эше дә союзның көндәлек эш практикасына әйләнергә тиеш. Музыка культурасын пропагандалау буенча Татгосиздат та күп кенә файдалы эш эшли ала. Профессиональ музыкантлар тарафыннан булсын, шулай ук музыка өлкәсендә үзлегеннән эш итүче иптәшләр тарафыннан булсын, безнең композиторларның әсәрләренә сорау гаять зур. Әгәр Татгосиздат бу сорауны искә алып, музыка әсәрләрен, аларның ноталарын бастырып тарату эшенә керешсә, һич шиксез, татар совет музыкасын пропагандалауда зур эш булачак һәм безнең яшь оешмабызга ярдәм булып төшәчәк.

Татарстан республикасының XX еллыгы уңае белән татар композиторлары алдында зур һәм әһәмиятле бурычлар торалар. Оештыру комитетына бу уңай белән аеруча җаваплы эшләр йөкләнә. Ул үз членнарының эшләрен күрсәтүне һәм республикабызның бәйрәмендә бай музыка сәнгате белән катнашуны тәэмин итәргә тиеш.

Бүген Татарстан композиторлары оешмасы алдында торган бурычларның кайберләре әнә шулар. Бу бурычларны уңышлы итеп хәл кылу музыка сәнгатен алга этәрәчәк, Татарстан композиторларының белем һәм тәҗрибәләрен киңәйтәчәк, аларның иҗад эшләрен тагын да югарырак художество биеклегенә күтәрәчәк, сәнгатнең зур һәм көчле бер тармагына — музыкага — халыкта тагын да көчлерәк мәхәббәт уятачак.

Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе
композитор: Нәҗип Җиһанов.

Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе
Москва Дәүләт Консерваториясе
укытучысы, профессор: Литинский.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.